# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларга таләпләрне төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 14 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында" 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, №1 (1); 2001, №3; 2002, №12 (II өлеш); 2004, №3 (IV өлеш); 2005, №4 (I өлеш); №7-8; Ватаным Татарстан, 2006 ел, 15 ноябрь) "фәнни, мөгаллимлек, әдәби һәм башка иҗат эшчәнлегеннән гайре, түләүле бүтән эшне башкара алмый."сүзләрен "мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән гайре, түләүле бүтән эшне башкара алмый. Мондый очракта күрсәтелгән эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, бары тик чит илләр, халыкара оешмалар һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый. Җәмәгать судьясы, әгәр Россия Федерациясе халыкара

шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, хөкүмәткә карамый торган коммерциячел булмаган чит ил оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керергә хокуксыз." сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы Конституция суды турында" 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясында (1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №11-12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, №11; 2001, №7-8; 2003, №10; 2006, 2 (I өлеш); 7 (I өлеш) "фәнни, мөгаллимлек, әдәби һәм башка иҗат эшчәнлегеннән гайре, түләүле бүтән эшне башкара алмый."сүзләрен "мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән гайре, түләүле бүтән эшне башкара алмый. Мондый очракта күрсәтелгән эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, бары тик чит илләр, халыкара оешмалар һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый. Судья, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, хөкүмәткә карамый торган коммерциячел булмаган чит ил оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керергә хокуксыз." сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

"Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, №6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: "Мондый очракта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлеге, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, бары тик чит илләр, халыкара оешмалар һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә

күзәтчелек советлары, хөкүмәткә карамый торган коммерциячел булмаган чит ил оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керергә хокуксыз." сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: "Мондый очракта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлеге, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, бары тик чит илләр, халыкара оешмалар һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый. Хисап палатасы аудиторлары, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, хөкүмәткә карамый торган коммерциячел булмаган чит ил оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керергә хокуксыз." сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16- ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1 өлешенә ( Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, №3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта "эшчәнлек белән шөгыльләнергә;" сүзләрен "эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Мондый очракта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлеге, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, бары тик чит илләр, халыкара оешмалар һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый." сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктта "әгъзасы булып торырга;" сүзләрен "әгъзасы булып торырга. Мондый очракта күрсәтелгән затлар, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, хөкүмәткә карамый торган коммерциячел булмаган чит ил оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керергә хокуксыз." сүзләренә алмаштырырга.".

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты

М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2007 елның 5 июле
№ 22-ТРЗ